Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Кәвәл авыл җирлеге Советының илле өченче утырышы

# КАРАР

28 октябрь, 2019 ел № 137

Физик затларның милкенә салым турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге нигезендә Кәвәл авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кәвәл авыл җирлеге территориясендә физик затлар милкенә мәҗбүри түләнергә тиешле салым билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Салым ставкаларын түбәндәге күләмдә билгеләргә:

2.1. **0,1** %:

- гаражлар һәм машина урынына;
- мәйданы 50 квадрат метрдан артмаган һәм шәхси ярдәмче хуҗалык, дача хуҗалыгы, яшелчәчелек, бакчачылык яки шәхси торак төзелеше алып бару өчен бирелгән җир кишәрлекләрендә урнашкан хуҗалык корылмалары яки корылмаларга карата;

2.2. **0,2 %**:

- фатир;
- бүлмә;
- торак йортларның бер өлешенш;
- фатир өлешләренең бер өлешенә.

2.3. **0,3 %**:

- торак йортларга;
- әгәр мондый объектлар торак йорт проектлаштырыла торган булса, тәмамланмаган төзелеш объектларына;
- составына бер генә булса да торак йорт кергән бердәм күчемсез комплексларга карата;

2.4. **2 %:**

Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларына;

Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектларына;

кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына карата;

2.5. Башка салым салу объектларына карата **0,5 %**.

3. Ике, өч яки дүрт фатирдан торган күпфатирлы бер катлы торак йортта фатирга милек хокукына ия булган физик затларга, әлеге фатирның гомуми мәйданының утыз квадрат метрына салым ставкасының процент өлеше буларак исәпләнгән салым суммасын киметү рәвешендә ташлама билгеләргә.

Әгәр фатирның гомуми өлешле милектә булса, ташламалар суммасы өлешле милектәге һәр кеше өчен әлеге фатирга милек хокукындагы өлешенә пропорциональ рәвештә исәпләнә.

Әгәр фатир уртак милектә булса, ташламалар суммасы уртак милектәге һәр кеше өчен исәпләнә.

Шул ук вакытта әлеге пункт нигезендә исәпләнгән ташлама суммасы исәпкә алынмаган салым суммасыннан артып китә алмый.

4. Физик затларның милкенә салым түләүдән азат итү:

4.1. 18 яшькә кадәрге дүрт һәм аннан да күбрәк балалары булган гражданнар;

4.2. әлеге пунктның 4.1 пунктчасында күрсәтелгән гражданнарның балалары.

5. Салым ташламасы түбәндәге салым салу объектларына:

1) фатир (фатирның бер өлеше, бүлмә) яки торак йорт (торак йортның бер өлеше);

2) гараж яки машина-урыннар.

Салым ташламасы, салым ташламаларын куллану өчен нигезләр санына бәйсез рәвештә, гаиләгә туры килә торган һәр төр салым салу объектына карата бирелә.

Салым ташламасы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кәвәл авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче (яшәү урыны буенча билгеләнгән тәртиптә теркәлгән) салым түләүчегә салым түләүче милкендә булган һәм эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган объектка карата салым түләүче тарафыннан түләнергә тиешле күләмдә бирелә.

Ташлама хокукына ия булган зат салым органына ташламалар бирү турында гариза һәм салым ташламасына хокукны раслаучы документлар, Россия Федерациясе Салым кодексында билгеләнгән срокларда тапшыра.

6. Кәвәл авыл җирлегенең 20.11.2014 ел, № 23 «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» Карарын (Советның 15.06.2015 № 16, 18.11.2016 ел, № 40, 25.05.2018 ел, № 95, 30.11.2018 ел, № 113, 28.03.2019 ел, № 125 карарлары редакциясендә) үз көчен югалткан дип танырга.

7. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») район газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

8. Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан, рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да соңга калмыйча үз көченә керә.

Питрәч муниципаль районы
Кәвәл авыл җирлеге башлыгы — А.Ф. Фәйзрахманов

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «КОВАЛИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ПЕСТРЕЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
СОВЕТ КОВАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1633000867